КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 175

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Академия» исеменә ия булган театрларда эшләгән өчен түләүләр турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 677 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Академия» исеменә ия булган театрларда эшләгән өчен түләүләр турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 677 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче» сүзләрен «2018 ел, 31 май, 413 нче» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2022 елларга» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга теркәлгән кушымтада:

«В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» юлында «9 316,1» саннарын «18 100,0» саннарына алыштырырга;

«Барлыгы» юлында «73 591,8» саннарын «82 375,7» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин